**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Какре-Елгинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

423320, Азнакаевский район,
с.Какре-Елга, ул.Советская, д.22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Кәкре-Елга авыл җирлеге башкарма комитеты**

423320, Азнакай районы,
Кәкре-Елга авылы, Совет урамы, 22
тел.8(855-92)37-0-49
E-mail:Kelg.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16 » февраль 2021 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 30.01.2019 елның 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган, административ регламентларга үзгәрешләр кертү хакында (09.08.2019 № 32, 27.02.2020 № 4, 29.04.2020 № 11, 25.11.2020 №32 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсен үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Кәкре Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең 30.01.2019 елның 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентлары турында» карары белән расланган, административ регламентларга (09.08.2019 № 32, 27.02.2020 № 4, 29.04.2020 № 11, 25.11.2020 №32 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Агач һәм куакларны, ябалдашларны кисүгә яисә агач утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында:

1.1.1. 2.5 пунктны түбәндәге эчтәлекле 9 пунктча белән тулыландырырга:

«9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турында салым органы белешмәсе.».

1.1.2. 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча белән тулыландырырга:

«2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.».

1.1.3. 2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга: «5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».

1.1.4. 3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша күчемсез мөлкәткә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан һәм аның белән алыш-биреш килешүләренең (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркем файдалана алырлык белешмәләр булган), законнарны бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурычларның барлыгы (булмавы) турында белешмәләр исемлекләрен бирү турында запрослар җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән запрос.».

1.1.5. 1 нче кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 8 нче пункт белән тулыландырырга:

«8) Салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына булмавы турында салым органы белешмәсе.».

1.2. Муниципаль милектәге җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион үткәрмичә урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентында:

1.2.1. 2.5 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турында салым органынының белешмәсе.».

1.2.2. 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычларның булмавы турында белешмә.».

1.2.3. 2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булу.».

1.2.4. 3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында запрослар җибәрә:

1) муниципаль хезмәт алучы юридик зат булган очракта, юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан күчермә;

2) әгәр муниципаль хезмәт алучы индивидуаль эшкуар булса, индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан кучермә;

3) җир кишәрлеге турында кадастр күчермәсе яисә җир кишәрлегенең кадастр паспорты;

4) элек төзелгән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча җир кишәрлегеннән фактта файдалануга түләү буенча бурыч барлыгы турындагы белешмәләр.Әлеге пунктчада билгеләнгән процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза кергән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

5) законнар бозган өчен салымнар, җыемнар, пенялар һәм штрафлар түләү буенча бурыч барлыгы (булмау) турында белешмәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: хакимият органнарына җибәрелгән запрослар.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http//pravo.tatarstan.ru. веб – адресы буенча урнаштыру юлы белән һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында http//aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык 

И.М.Мөхәмәтҗанов